**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«08» декабря 2020г** **№ 31**

**Биектау муниципаль районының Дөбъяз авыл җирлеге Советы депутатының ышанычын югалтуга бәйле рәвештә вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату (вазыйфасыннан азат итү) турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясындагы 10.1 өлешенә, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 13.1 статьясындагы 1 өлешенең 1, 2 пунктына, Биектау муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Президентының 2020 елның 4 декабрендә кергән 01-10945 номерлы «Депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында» гаризасы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Коррупциягә каршы тору турындагы законнарны бозулар җибәргән өчен 10 нчы номерлы сайлау округы буенча дүртенче чакырылыш Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советы депутаты Низамов Әсхәт Санатулла улының ышаныч югалтуга бәйле рәвештә вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатырга (вазыйфасыннан азат итәргә).
2. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.
4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Совет рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин